**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ**
**КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**31.01.2020** **Чирмешән авылы** **№ 22**

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районында**
**җирләү буенча хезмәтләрнең**
**гарантияле исемлеге нигезендә**
**күрсәтелә торган хезмәтләрнең**
**хакын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы «Җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль закон, 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы «Татарстан Республикасында «Җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында»Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, 2020 елның 29 гыйнварындагы 61 номерлы «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. 2020 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә Чирмешән муниципаль районында күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1, 2, 3 номерлы кушымталар нигезендә 6124,86 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында" 2019 елның 31 гыйнварындагы 30 номерлы карары (2019 елның 8 февралендәге 62 номерлы үзгәрешләр белән) үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе И.Н. Шәйдуллин

Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 31 гыйнварындагы
22 номерлы карарына
1нче Кушымта

2020 елның 1 февраленнән ТР Чирмешән муниципаль районында җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе
исемлеге

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе *(сум)*** |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2.Җирләү өчен табут һәм башка кирәк-яраклар бирү һәм китерү | 2228,52 |
| 3.Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 1020,83 |
| 4.Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2875,51 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |

Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 31 гыйнварындагы
22 номерлы карарына
2нче Кушымта

2020 елның 1 февраленнән ТР Чирмешән муниципаль районында
җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе
исемлеге

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе *(сум)*** |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2.Кәфенләү | 232,12 |
| 3. Җирләү өчен табут һәм башка кирәк-яраклар бирү һәм китерү | 1996,40 |
| 4.Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 1020,83 |
| 5.Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2875,51 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |

Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 31 гыйнварындагы
22 номерлы карарына
Знче Кушымта

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында, авыл җирлекләрен дә кертеп, 2020 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган җирләү буенча хезмәтләрнең бәясе

| № п/п | Авыл җирлекләре исемнәре | Җирләү буенча гарантияле исемлектәге хезмәтләрнең бәясе, сум |
|---|---|---|
| 1 | Бәркәтә авыл җирлеге | 6124,86 |
| 2 | Югары Кәминкә авыл җирлеге | |
| 3 | Ивашкино авыл җирлеге | |
| 4 | Кармыш авыл җирлеге | |
| 5 | Күтәмә авыл җирлеге | |
| 6 | Лашман авыл җирлеге | |
| 7 | Мордва Афонькәсе авыл җирлеге | |
| 8 | Түбән Кәминкә авыл җирлеге | |
| 9 | Түбән Кармалка авыл җирлеге | |
| 10 | Яңа Элмәле авыл җирлеге | |
| 11 | Яңа Кади авыл җирлеге | |
| 12 | Иске Кади авыл җирлеге | |
| 13 | Иске Котыш авыл җирлеге | |
| 14 | Иске Үтәмеш авыл җирлеге | |
| 15 | Түймәт авыл җирлеге | |
| 16 | Ульяновка авыл җирлеге | |
| 17 | Чирмешән авыл җирлеге | |
| 18 | Шешминка авыл җирлеге | |